МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**26.08.2021** г.Казань **№ 209/2 - пр**

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2020 елның 22 апрелендәге 99/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан тану хакында

“Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 134 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үз көчләрен югалткан дип тану турында” 2021 елның 16 августындагы 738 номерлы карары нигезендә б о е р а м:

1. “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2020 елның 22 апрелендәге 99/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы С.М. Нигъмәтҗановка әлеге Боерыкны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Л.Н. Гариповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров